МЭР ГОРОДА
НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
ХАКИМЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30 июль 2015 ел №1245

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуга әзерләнү һәм аны үткәрү турында

«Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 108–ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны оештыру турында» 2013 елның 10 апрелендәге 316 номерлы карары, Татарстан Республикасының «2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны үткәрүгә әзерләнү өчен муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2014 елның 14 маендагы 31-ТРЗ номерлы законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм үткәрү турында» 2015 елның 18 июлендәге 523 номерлы карары нигезендә һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны оештыру, әзерләү һәм үткәрү максатында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуга әзерләнү һәм үткәрү буенча комиссия төзергә.

2. Расларга:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуга әзерләнү һәм үткәрү буенча комиссия турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуга әзерләнү һәм үткәрү буенча комиссия составын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе Н.Г. Мәһдиевкә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме
вазыйфаларын башкаручы Ф.И. Андреева

Шәһәр Хакименең
2015 елның 30 июлендәге
М 245 номерлы карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы
исәбен алуга әзерләнү һәм үткәрү буенча комиссия турында
нигезләмә

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуга әзерләнү һәм үткәрү буенча комиссия (алга таба – Комиссия) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны оештыру, әзерләү һәм үткәрү өчен төзелгән.

2. Комиссия үз эшендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив-хокукый актларга, шәһәр Уставына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Комиссиянең төп бурычлары булып тора:

1) 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм уздыру буенча Башкарма комитет тармак (функциональ) һәм территориаль органнарының, федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарының килештерелгән гамәлләрен тәэмин итү;

2) Яр Чаллы шәһәре территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуга әзерлек һәм аны үткәрүгә бәйле мәсьәләләрне оператив хәл итү;

3) авыл хуҗалыгы исәбен алу объектлары исемлекләрен төзүдә ярдәм күрсәтү;

4) халык арасында мәгълүмати-аңлату эшләрен оештыру, авыл хуҗалыгы исәбен алу максатларына аңлатма бирү;

5) авыл хуҗалыгы исәбен алу объектлары турында мәгълүмат җыюга гражданнарны җәлеп итүдә ярдәм итүне тәэмин итү;

6) исәпкә алу объектлары турында мәгълүмат җыючы затлар эшләү өчен биналарның әзерлеген кабул итү.

4. Комиссия хокуклы:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм уздыру барышы турында Башкарма комитетның тармак (функциональ) һәм территориаль органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары җитәкчеләрен һәм башка вазыйфаи затларын тыңларга;

2) билгеләнгән тәртиптә федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарыннан, Башкарма комитетның тармак (функциональ) һәм территориаль органнарыннан кирәкле документларны соратып алырга;

3) федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына, Башкарма комитетның тармак (функциональ) һәм территориаль органнарына 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алу мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр җибәрергә;

4) 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм уздыру мәсьәләләрен хәл итү өчен комиссия утырышларына Башкарма комитетның тармак (функциональ) һәм территориаль органнары, федераль башкарма хакимият

органнарының территориаль органнары җитәкчеләрен, авыл хуҗалыгы предприятиеләре, бакчачылык һәм яшелчәчелек коммерцияле булмаган берләшмәләре вәкилләрен чакырырга;

5) комиссиягә йөкләнгән бурычларны хәл итү белән бәйле проблемалар буенча аерым тәкъдимнәр эшләү өчен вакытлы эш төркемнәре төзергә.

5. Комиссия составы Яр Чаллы шәһәре Хакиме карары белән раслана.

6. Комиссия Комиссия рәисеннән, ике урынбасардан, Комиссия әгъзаларыннан һәм секретарьдан тора.

Комиссия рәисе Комиссия эшчәнлеге белән җитәкчелек итә, мәсьәләләрне карау тәртибен билгели, комиссиянең эш планнарын раслый, Комиссия составын аныклау һәм яңарту турында тәкъдимнәр кертә, аның утырышларын алып бара, Комиссиягә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен шәхси җаваплылык тота.

Комиссия рәисе булмаганда яисә аның кушуы буенча рәис вазыйфаларын Комиссия рәисе урынбасарларының берсе башкара.

7. Комиссия утырышлары кирәк булган саен, әмма Комиссия рәисе раслаган эш планы нигезендә ярты елга бер тапкыр үткәрелә. Комиссия утырышлары, әгәр аларда аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала.

8. Комиссия карарлары утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта Комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

Комиссия карарлары Комиссия рәисе яки утырышта рәислек итүче урынбасар имзалаган беркетмәләр итеп утырыш уздырылган көннән башлап өч көнлек срокта рәсмиләштерелә.

Шәһәр Хакименең
2015 елның 30 июлендәге
М 245 номерлы карарына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуга әзерләнү һәм үткәрү буенча комиссия составы

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Андреева Флера Ивановна | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башлыгы урынбасары, Шәһәр Хакиме вазыйфаларын башкаручы, комиссия рәисе; |
| 2. | Мәһдиев Наил Гамбәр улы | Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе, комиссия рәисе урынбасары; |
| 3. | Кропотова Наталия Анатольевна | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм итү идарәсе башлыгы, комиссия рәисе урынбасары; |
| 4. | Әхтәмова Гөлнара Сәетҗан кызы | Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт статистикасы бүлеге башлыгы, комиссия секретаре (килешү буенча); |
| | комиссия әгъзалары: | |
| 5. | Абдуллин Ринат Әзһәр улы | Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары; |
| 6. | Әхмәтова Гөлнар Карл кызы; | Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты Аппараты Җитәкчесе; |
| 7. | Быданова Татьяна Александровна | «Яр Чаллы шәһәре халкын эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ директоры (килешү буенча); |
| 8. | Гаврилов Владислав Анатольевич | Башкарма комитетның Комсомол районы Хакимияте Башлыгы; |
| 9. | Галиәкбәрова Әлфинур Азат кызы; | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы; |
| 10. | Галимов Искәндәр Нургаләм улы | Башкарма комитетның Үзәк районы Хакимияте Башлыгы; |
| 11. | Гатина Лилия Назыйм кызы | ТР Яр Чаллы шәһәре буенча ФСХИ башлыгы (килешү буенча); |
| 12. | Закирова Лира Вәли кызы | "Ростехинвентаризация-Федеральное БТИ" ФДУП ТР буенча Яр Чаллы бүлекчәсе башлыгы (килешү буенча); |

| | | |
|---|---|---|
| 13. | Кыямов Рафаил Әгъләметдин улы | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы; |
| 14. | Колесникова Татьяна Владимировна | Хаким Аппаратының массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү бүлеге башлыгы; |
| 15. | Кудряшова Люция Маркасовна | Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы; |
| 16. | Мингалимова Гөлнара Галимҗан кызы; | ТИБ РДУП 8 нче районара филиалы директоры (килешү буенча); |
| 17. | Нигъмәтуллин Ирек Абзал улы | «Яр Чаллы шәһәре дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ башлыгы (килешү буенча); |
| 18. | Сиринова Наталья Анатольевна | «ФКП Росреестр» ФДБУ филиалының ТР Яр Чаллы шәһәре буенча 16 нчы территориаль бүлек башлыгы (килешү буенча); |
| 19. | Соколов Алексей Владимирович | Россия ЭЭМ Яр Чаллы шәһәре буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча); |
| 20. | Солтанова Рәисә Кәүсәр кызы | Башкарма комитет икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм итү идарәсенең кулланучылар базары бүлеге башлыгы; |
| 21. | Усманова Раушан Мәсгуть кызы | Башкарма комитетның Автозавод районы Хакимияте Башлыгы; |
| 22. | Фәсхетдинов Радик Рөстәм улы | ТР Росреестр идарәсенең Яр Чаллы бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| 23. | Хәлимов Рамил Мәрван улы | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын башкаручы, мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе башлыгы |